**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь, 2024 ел** **№10**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Иске Каенсар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 27 ноябрендә 8 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Иске Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын ТР, Кукмара районы, Иске Каенсар авылы, Яшел ур., 19 йорт адресында урнашкан 19 нчы йорт каршында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Иске Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация һәм контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Иске Каенсар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре),*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*

*(Иске Каенсар авылында Тынычлык урамына елга аша чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Иске Каенсар авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре*);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау *(Иске Каенсар авылындагы Яшел урамыннан Тынычлык урамына елга аша җәяүлеләр күперен ремонтлау, проект-смета документлары, башка эш төрләре);*

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү *(Иске Каенсар авылында янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары)*

«РИЗА» «КАРШЫ» - кабул ителгән дип исәпләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

5. Важашур авылы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы: П.Л. Иванов